“Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чури-Бураш авыл җирлегенең Чури-Бураш авылында халык җыены нәтиҗәләре һәм 2024 елда үзара салым кертү турында» 2023 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы карарын үзгәртү буенча халык җыены нәтиҗәләре турында”

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чури-Бураш авыл җирлегенең Чури-Бураш авылында 2024 елның 20 мартындагы 101 номерлы халык җыены карары

“Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Чури-Бураш авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда халык җыенын әзерләү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 10 сентябрендәге 91 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Чури-Бураш авыл җирлеге Советы карарыны туры китереп

2024 елның 20 мартында үткән “Сез Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чури-Бураш авыл җирлегенең Чури-Бураш авылындагы халык җыенының нәтиҗәләре һәм 2024 елда үзара салым кертү турында» карарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча эшләр исемлеге өлешендә үзгәртү һәм 2024 елда алынган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктыртуны көйләү;
- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү;

дигән мәсьәлә буенча Чури-Бураш авылы халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзеде.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә буенча:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 246 кеше кертелгән, тавыш бирүдә кеше катнашкан гражданнар саны 175 кеше .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда 175 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чури-Бураш авыл җирлегенең Чури-Бураш авылында халык җыенын узган дип, халык җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2.Халык җыенында карарлган мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. 2024 елда алынган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлдерергә:

- урамнарны яктыртуны көйләү;
- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

- торак пункт территориясен төзекләндерү;

4.Әлеге карарны мәгълүмат стендындлары аша халыкка белдерергә  һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Чури-Бураш авыл
җирлеге Башлыгы                                        И.Р.Мифтахов